ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
НУРЛАТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КОЛБАЙ-МОРАСА АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

# КАРАР

№ 20 «28» май 2021 ел

## Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлегендә җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләренә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 33 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 өлешенең 20 пункты, «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен раслау турында» 2014 елның 17 февралендәге 82 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының Колбай-Мораса авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең җирдән файдалану һәм төзелешләр кагыйдәләрен раслау турында» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Кагыйдәләрнең 4 статьясындагы 13 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Шәхси торак төзелеше өчен җир кишәрлекләренең чик күләме:

җир кишәрлегенең максималь күләме - 1500 кв.м;

җир кишәрлегенең минималь күләме - 1000 кв.м.

Шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару өчен җир кишәрлекләренең чик күләмнәре:

җир кишәрлегенең максималь күләме - 5000 кв.м;

җир кишәрлегенең минималь күләме - 1000 кв.м.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә бастырырга, шулай ук Нурлат муниципаль районының рәсми сайтында http://nurlat.tatarstan.ru/ урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Татарстан Республикасы
Нурлат муниципаль районы
Колбай-Мораса авыл җирлеге
Советы Рәисе Р.Ә. Насыйбуллин